ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕСАЛТАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422645С.Большой Салтан,
ул. Р.Шарафеева, дом 59

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ СОЛТАН АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422645, Олы Солтан авылы,
Р.Шәрәфи урамы, 59 нчы йорт

Тел.: (84361) 27542, факс: (84361) 27542, e-mail: Bslt.Rs@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 мая 2023 Олы Слотан ав. № 9

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 20 октябрендә кабул ителгән “Социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан торак урыннары алмашу буенча документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 13 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022елның 15 августындагы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында " 1415 номерлы карарына тәңгәлләштереп, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 20 октябрендә кабул ителгән “Социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан торак урыннары алмашу буенча документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 13 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11абзацның 3.3.2.1. пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Формалаштырылган мөрәҗәгать, мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгатьнең электрон формасындагы һәр кыры тутырылып бару процессында, формат-логик тикшерү Бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә башкарыла. Бердәм портал тарафыннан электрон формадагы мөрәҗәгатьнең дөрес тутырылмаган булуы ачыкланганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры мөрәҗәгатьнең электрон формасындагы мәгълүмати хәбәр аша җиткерелә.».

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Солтан авыл җирлегенең Олы Солтан авылы, Р.Шәрәфиев урамы, 12 йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан

Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Солтан авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Сөнгатуллин